ГЛАВА
МАЛЬБАГУШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Нефтяников, д30, с.Мальбагуш,
Азнакаевский муниципальный
район 423330

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МӘЛБАГЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ БАШЛЫГЫ

Нефтяниклар ур., 30 нче йорт,
Мәлбагыш авылы, Азнакай муниципаль
районы, 423330

Тел./факс(885592)3-77-90,3-77-91; E-mail:Malb.Azn@tatar.ru,

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

от 02 июнь 2025 ел　　　　　　　　　　　　　　　　　№ 2

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлегенең Мәлбагыш торак пунктында гражданнар җыенының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлегенең Мәлбагыш авылында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2024 елның 23 ноябрендәге 2 номерлы карарына, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлегенең Мәлбагыш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 23 ноябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Мәлбагыш авыл җирлеге Уставының 15.1 статьясы, Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башлыгы карар кабул итте:

1. Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлегенең Мәлбагыш торак пунктында «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлегенең Мәлбагыш авылында 2025 елда гражданнарның үзара салым кертү турында» 2024 елның 23 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлегенең Мәлбагыш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 23 ноябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2025 елның 16 июнендә 13 сәгать 00 минутка гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертүгә ризамы:

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлегенең Мәлбагыш торак пунктында гражданнар җыененың «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлегенең Мәлбагыш авылында 2025

елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2024 елның 23 ноябрендәге 2 номерлы карарына, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлегенең Мәлбагыш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 23 ноябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында», чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

« 1) тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (тышкы яктырту урам челтәрләрен карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү; лампалар, электр саклый торган яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җайланмалар сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырткычларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

2) торак пункт территориясен төзекләндерү (территорияне чабу, чистарту, чүп җыю хезмәтләре өчен түләү; тракторчыга механикалаштырылган кар җыю хезмәтләре өчен түләү);

3) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Яңа материал өстәп юлларны профильләштерү, Комсомол урамындагы юлларга асфальт салу; Кооператив урамындагы, Малля урамындагы автомобиль юлларын төзү һәм ремонтлау)»

« ӘЙЕ» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Азнакай муниципаль районының мәгълүмат стендларында һәм http://aznakayevo.tatarstan.ru адресы буенча рәсми сайтында, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Башлык А.Й.Әхмәтшин